СОВЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)93-1-24, факс (84366)93-1-24. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеже авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**25 октябрь 2021 ел** **№ 6**

**Арча муниципаль районы Сеже авыл җирлеге Починок- Поник авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеже авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Сеже авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1.Арча муниципаль районы Сеже авыл җирлеге Починок -Поник авылында Починок- Поник авылы, Ф.Бикбаев урамы, 15 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2021 елның 10 ноябренә 12 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2022 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Сеже авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан ,1нче группа инвалидлардан һәм 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, автоматлар, контакторлар сатып алу һәм урнаштыру;

- Кесмәс елгасы күпереннән башлап ком карьерындагы тауга кадәр юл полотносына нигез салу һәм вак таш җәю (2 этап);

- МТЗ 82.1 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алуны финанслашу (борылышлы гидравлик отвал, үзбушаткыч тагылма, чапкыч, фронталь эленмәле төягеч сәнәге, чүмечле фронталь эленмәле төягеч);

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

3. Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Починок- Поник авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Починок- Поник авылы, Ф.Бикбаев урамы, 15 нче йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Р.В.Хәмидуллин

СОВЕТ СИЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ИНН1609012692